Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Ошторма-Юмья авыл җирлеге
Советы

КАРАР

«29» июль, 2026 ел № 16

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Кукмара районы прокурорының 2026 елның 22 июнендәге 02-08-01 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә (2025 елның 15 апрелендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.9. пунктының беренче абзацында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» «мобиль кушымтасыннан файдалану,» сүзләрен өстәргә;

1.2. 3.11 пунктының дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында, башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.».

Җирлек башлыгы: С.В. Тимофеев